(45), *балдак* – кольцо (49), *бүрек* – шапка (55), *бөрмәле кәзәки* – поддёвка (56), *түбәтәй* – тюбетей, чеплашка, ермолка (70), *ката/киез ката* – валеныя галоши (153), *кафтан/чикмән* – кафтанъ (162) и т.д.

**Музыкальные инструменты:** *эскрибкә* – скрибка (24), *эскрибкә таягы* – смычокъ (24), *уен аләте* – музыкальный инструментъ (39); *бизәк* – узоръ, украшеніе (60), *думбра* – домбра (балалайка) (109), *саз* – арфа, лира (115), *сорнай* – цитра, арфа (116), *кубыз* – кобза (163), *курай* – флейта, кларнетъ (165), лира (182) и т.д.

**Слова связанны военным делом:** *алтатар (алты атар)* – револьверъ, пистолетъ (16), *ук* – стрѣла (35), *барут/дары* – порохъ (47), *җәдрә* – пуля (ядро) (80), *дар агачы* – висѣлица (106), *силах/корал* – оружіе (117), *сөңге* – копьё (гарпунъ) (120), *туб* – орудіе, пушка (140), *кылыч* – сабля, шашка (163), *кылыч кынысы* – ножны (163), *мылтык* – ружьё (190) и т.д.

**Предметы ритуалов**: *аркылы/салиб/тәре* – крестъ (9), *таҗ* – корона, вѣнецъ (63), *табут* – гробъ (63), *тәхет* – тронъ, престолъ (65), *тәсбих* – четки (66), *тәре* – крестъ, икона, образъ (74), *чардуган* – могильная, надгробная изгородь (89), *хач/кач/тәре/салиб* – крестъ (102), *кәфен* – саванъ (171), *намазлык* – простыня, на которомъ совершаютъ молитву (195) и т.д.

Таким образом, язык является хранителем национальной культуры, в нем накапливается человеческий опыт и передается из поколения в поколение. В свое время Вольтер писал: «Словарь – это вселенная в алфавитном порядке». Эти слова стали крылатыми, в них очень точно сделан акцент на огромном информационном и культурном потенциале лексикографических изданий [Козырев, 2004: 5].

**Литература**

Козырев, В.А. Русская лексикография / В.А. Козырев, В.Д. Черняк. – М.: Дрофа, 2004. – 288 с.

Миннуллин, К. Татарский язык в словарях / К. Миннуллин, Р. Валиуллин. – Казань: Мастер Лайн, 1998. – 56 с.

Рахманколый, С. Татарча-русча лөгать / С. Рахманколый. – Казан: И.Н. Харитонов лито-типографиясе, 1913. – 210 с.

***Өнәр Мостафа***

Эгей университеты, Измир

## ПРОФЕССОР, ДОКТОР ӘДҺӘМ РӘХИМ УЛЫ ТЕНИШЕВНЫҢ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*Статья посвящена к 90-летию со дня рождения члена-корреспондента РАН, профессора Эдгема Рахимовича Тенишева. Рассматриваются основные направления научной деятельности великого ученого,*

*его вклад в развитие истории тюркских языков, лексикологии, различные аспекты диалектологии.*
**Ключевые слова:** *Тенишев Э.Р., юбилей, история, тюркские языки, диалектология, этнография, лексикология*
*The article is devoted to 90th anniversary of corresponding member of RSA, professor Edgem Rakhimovich Tenishev. The author examines the main ways of scientific work of the outstanding scholar, his heritage of the history of the Turkic languages development, lexicology and different aspects of dialectology.*
**Key words:** *Tenishev, anniversary, history, the Turkic languages, dialectology, ethnography, lexicology.*

Әдһәм Рәхим улы Тенишев 1921 елның 25 апрелендә Иделнең көнбатышында, татарлар тупланып яшәгән Пенза шәһәрендә дөньяга килә. Аларның зыялы гаиләсендә, илдә барган авыр вакыйгаларга, гражданнар сугышы булуга карамастан, балаларга милли һәм дөньяви белем бирүгә зур игътибар бирелгән. Кечкенәдән гарәп язуында иске татар әдәби телендәге әсәрләрне укыган. Әдһәм Рәхим улы истәлекләрендә апасы Әйшә белән өйдә Рабгузыйның «Кыйсас-әнбия»дән өзекләр укуларын искә алган. Шулай ук Пензада туганнары, татар халкының атаклы шәхесләре Муса Бигиев һәм Заһир Бигиевләр дә яшәгән.

Октябрь инкыйлабы аларның бердәм гаиләсенә тәэсир ясамый калмый. Аларның зур өйләренә чит кешеләрне урнаштыралар, иң кызганычы, бай китапхәнәләрен макулатурага тапшырталар. Әтисе Рәхимнең НЭП вакытында сабын ясый торган фабрика ачуы билгеле, әмма аны да соңрак дәүләт үз карамагына алган. Бу вакыйгалардан соң Тенишевлар гаиләсе Кыргызстан өлкәсендәге Җәлалабад шәһәренә күченәләр. Бу мәҗбүри күченеш, булачак тюрколог Әдһәм Рәхим улының киләчәк язмышы өчен мөһим чор була – кечкенә Әдһәм монда кыргыз телен үзләштерә. Үсмерлек елларында Ә.Р. Тенишев XIX гасырның бөек тюркологы, маҗар галиме А. Вамбериның «Урта Азиягә сәяхатнамә»се белән таныша. Укуын Тенишев туган ягында тәмамлый, 1938 елда Мәскәү транспорт институтының математика факультетына укырга керә һәм 1941 нче елны аның интеграллар хакындагы фәнни мәкаләсе басыла.

II Дөнья сугышы Э.Р. Тенишев карьерасына зур бер үзгәреш кертә. Аны сугышка алмыйлар, ул, Пензага кайтып, элемтә бүлегендә эшли башлый. Кечкенәдән гаиләдә салынган милли тәрбия Әдһәм Рәхимовичны көнчыгыш мәдәниятне өйрәнүгә этәрә, 1945 елның мартында Ленинград университетының Көнчыгыш факультетына укырга кабул ителә. Император Академиясе традицияләрен дәвам иткән әлеге уку йортында С.Е. Малов, В.М. Жирмунский, Н.К. Дмитриев һәм А.Н. Кононов кебек бөек тюркологлар эшләгән. Фәнни җитәкчесе иске төрки телләр, хәзерге төрки шивәләр өлкәсендә танылган тюрколог С.Е. Малов булган. 1949 елда Ә.Р. Тенишев

«Кыпчакский язык и его связь современными кыпчакскими языками» (Кыпчак теле һәм аның хәзерге телләр белән мөнәсәбәте) дип аталган кандидатлык диссертациясен яклый.

Әдһәм Рәхим улы уку елларында булачак хатыны Ленинград университетының рус филологиясе бүлеге студенты Елена Александровна белән таныша. Е. Тенишева үзенең истәлекләрендә филармония концертларына йөрүләре, тимераякта шуарга яратулары хакында уртаклашкан.

Укытучысы С.Е Маловның өендә уздырыла торган фәнни түгәрәкта В.М. Жирмунский, А.Н. Кононов, В.М. Наделяев, А.М. Щербак кебек булачак галимнәр арасында Ә.Р. Тенишев та була. В. Радловның фәнни дәвамчысы С. Малов Урта Азиядә, Төркестанда булган, иске уйгыр язма истәлекләре, һәм, бигрәк тә, «Алтын Ярук» ядкәрен өйрәнү белән шөгыльләнгән. Ә.Р. Тенишевның докторлык диссертациясе темасы итеп «Грамматический очерк языка сочинения Золотой Блеск» (Л.,1953) сайлавы, әлеге ядкәрнең тел үзенчәлекләрен өйрәнүе очраклы хәл түгел, ә бәлки җитәкчесенең тәэсире булса кирәк. Яшь галим Ленинград көнчыгыш институтында эшли башлый, чит телләрне камилләштерүгә, бигрәк тә, немец һәм француз телләрен өйрәнүгә зур игътибар бирә. 1954 нче елда укытучысы Н.К. Дмитриевның чакыруы буенча Мәскәүгә Тел белеме институтының төрки телләр бүлегенә күчә. Бүлектә Э.В. Севортян, Е.И. Убрятова, Н.А. Баскаков, Ф.Г. Ушаков кебек танылган галимнәр белән бер коллективта эшли башлый. Яшь галим Ә.Р. Тенишев хатыны Елена Александровна белән Мәскәүдә бернинди уңайлыклары булмаган бер бүлмәгә урнашалар. Тиздән Мәскәүдәге Тел белеме институтына танылган венгр тюркологы Юлиус Немет килә. Мәскәүдә аның ярдәмчесе, озатып йөрүчесе итеп, Әдһәм Рәхимович билгеләнә; икесе дә иске төрки язма истәлекләрне, кыпчак диалектларын өйрәнә, шуның өстенә, икесенең дә төрек телендә аралаша алулары исәпкә алына. Ленинградта булганда, атаклы маҗар галимен Ә. Тенишев остазлары профессор С.Е. Малов һәм И.И. Мещанинов белән таныштыра.

1956 елда Советлар Союзының Фәннәр академиясенә Кытай Халык Республикасыннан рәсми чакыру килә. Анда Кытайда тюркология фәнен үстерү өчен ике елга белгеч чакырыла. Россия Фәннәр академиясе, кадрлар әзерләүдә булышу өчен, Әдһәм Рәхим улын Пекинга җибәрә. Әдһәм Тенишев, педагогик эшчәнлек белән беррәттән, фәнни эзләнүләрен дәвам итә. Бу илдә яшәп, саларлар һәм сарыг уйгурлар яшәгән төбәкләргә барып, бай тел һәм фольклор материалы туплый. 1956 елның ахырында уйгыр диалектларын өйрәнер өчен, Синьцзянга, 1957 елның җәендә исә, саларлар яшәгән Тсинхауга һәм сары уйгурлар күпләп яшәгән Гансуга фәнни экспедициягә чыга. 1959 елда Мәскәүгә кайтканда, галим әле моңа кадәр өйрәнелмәгән төрки халыклар хакында бай материал туплаган була. Ә.Р. Тенишевның эшчәнлегендә саларлар һәм сарыг-уйгурларның теле

хакындагы хезмәтләре аерым урын тота, тюркология фәнен яңа материал белән баета. Бу өлкәгә караган хезмәтләре: Саларский язык (М., 1963; Саларские тексты (М., 1964); Язык желтых уйгуров (М., 1966).

1969 елда, салар теленнән туплаган материаллары нигезендә, докторлык диссертациясен яклый, 1976 елда әлеге хезмәт аерым китап булып басыла. Шул рәвешле, бу көнгә кадәр уйгур, төркмән телләренең бер диалекты итеп каралган салар теленең аерым бер төрки тел булуы исбатлана, әдәби телнең ике диалекты билгеләнә.

Яшь профессорның 1976 елда «Строй сарыг-югурского языка» китабы нәшер ителә. Әлеге хезмәтләрендә Э. Тенишев салар һәм сарыг-уйгур телләренең статусын билгели, кытай, тибет телләренең йогынтысын ачыклый. Тел үрнәкләре арасында tastar «ташлар»; erenner «ирләр» кебек кыпчак, analer «аналар» һәм gerlar «чынаяклар, савыт» кебек угыз тел күренешләре бар, шулай ук тәңгәл килмәгән очраклар да китерелгән; kotıtan «гыйнварыннан»; sutan «судан» кебек интервокаль позициядә саңгыраулашу küzdin «күздән»; ınısınınkidin «туганныннан» кебек борынгы әдәби тел үзенчәлекләре саклануы күрсәтелгән [Тенишев, 1976: 12-20]. Беренче бүлектә сары (Sari) уйгурларның, икенче булектә шира (Şıra) уйгурларның телләре, фонетикасы һәм сүзлеге Ә. Тенишевка хас төгәллек белән эшләнгән. Галимнең укучысы Анна Дыбоның әйтүенчә: «Ә. Тенишевның фәнни тикшерүләренең яңалыгы һәм тирәнлеге әһәмиятле булган кебек, алдагы буын тикшерүчеләр өчен диалектны аерып чыгару прицибларын һәм критерийларын билгеләве белән хезмәт аеруча кыйммәтле».

1963 елдан Мәскәүдә Ә.Р. Тенишев җитәкләгән төрки һәм монгол телләре бүлегендә төрки телләрнең тарихи-чагыштырма грамматикасының алты томлыгын хәзерләүгә керешәләр. В. Радлов һәм Н. Катанов кебек Россия тюркологларының XIX гасырда бу юнәлештәге саллы фәнни хезмәтләрен беләбез. Алардан соң 1950 елларда Н.К. Дмитриев җитәкчелегендә дөнья күргән «Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков» коллектив хезмәтнең фонетика (1955), морфология (1956), синтаксис (1961) һәм лексика (1962) бүлекләре аерым монографияләр буларак нәшер ителеп, дөнья фәне казанышына әверелгән иде.

Ә.Р. Тенишев остазы Н.К. Дмитриевның фәнни мирасын лаеклы дәвам итте. Төрки тел фәненең казанышларына таянып, борынгы төрки тел күренешләрен реконструкцияләү каралган күптомлыкның программасы төзелеп, бүлек галимнәре белән аерым томнар өстендә эш башланды. Галим үзе исән чакта «Сравнительно-историческая грамматика» хезмәтенең дүрт томы: Фонетика (1984, 485 б.), Морфология (1988, 560 б.), Лексика (1977; 2001, 822 б.) нәшер ителә. Калган томнарны төзү шулай ук танылган галим, җитәкче Әдһәм Рәхимович белән башлана: «Региональные реконструкции» (2002, 767 б.); «Пратюркский язык основа; Картина мира пратюркского этноса по данным языка» (2006, 912 б.), тик бөек галим аларның басылып чыгып,

тюркология фәнен иң югары баскычка күтәргән хезмәт буларак бәя алуын күрергә өлгерми.

С.Е. Маловның студент елларында иске төрки тел, уйгур теленнән биргән дәресләрен, белемен фәнни тормышында кулланган, шулар нигезендә яңа ачышлар ясаган галим, остазының лаеклы укучысы, дәвамчысы була профессор Ә.Р. Тенишев. Укытучысы Н.К. Дмитриев башлаган чагыштырма тюркологик юнәлештәге эзләнүләрне чагыштырма-тарихи юнәлеш буларак үстергән, күптомлык хезмәт иттереп бастырып чыгаруга ирешкән бәхетле галим ул Әдһәм Рәхим улы.

80 елларда чыккан чагыштырма-тарихи хезмәтнең «Лексика» (1997, 2001) томы эчтәлеге белән этимологик сүзлеккә туры килүен белгертергә кирәк; тематик төркемнәр бер тезаурус тәшкил иткән хезмәттә борынгы төрки сүзләрне, хәзерге кардәш төрки телләрдән лексик берәмлекләрне, ягъни тарихи һәм яңа тел материалларын бер эзлеклелектә күрергә була. Бу хезмәткә кадәр совет тюркологиясендә иң танылган тел тарихы чыганагы булып «Древнетюркский словарь» (Л.1969) санала иде. Дүрт төзүче авторның (В.М. Наделяев, Д.М. Насилов, А.М. Щербак, Ә.Р. Тенишев) берсе булган лексикологыбыз, Төрки дөньяның уртак мирасына үзеннән зур өлеш кертте.

Әлеге фәнни юнәлешләр белән генә чикләнми галим эшчәнлеге. Ул җитәкләгән Тюркология бүлеменең уңышлы эшчәнлеге дә мәрхүм профессорның тырыш хезмәт җимеше.

1977 елда Әдһәм Рәхим улы Тенишевны Европаның лингвистик атласы – халыкара ЮНЕСКО оешмасы редколлегиясенә кабул итәләр.

Тюркология фәнендә иң абруйлы «Советская Тюркология» журналы 1970 елның 1 апрелендә нәшер ителә башлаган. Фәннәр Академиясенең басма органы булган әлеге журналның 1989 кадәр елга алты номеры чыгып килгән, хөрмәтле Ә.Р. Тенишев аның соңгы баш редакторы (1987 ел, август). Тюрколог галим 1990 елда «Эпос народов СССР» фундаменталь сериянең баш редакторы була, соңрак «Евразия халыклары дастаны» аталган әлеге сериядә Ә.Р. Тенишев редакторлыгында кыргыз, карачай-балкар, карел-фин, бурят дастаннары нәшер ителә. 1995 елда «Манас»ның 1000 еллык халыкара бәйрәменә өченче, дүртенче томнары әзерләп бастырыла.

1997 елда Бишкектә басылган «Языки мира» (Дөнья Телләре) сериясенең төзүчесе һәм баш редакторы Тенишев Әдһәм Рәхим улы. Бу хезмәттә мөхтәрәм галимнең алты зур күләмле мәкаләсе – алтай телләр бердәмлеге, борынгы төрки ядкәрләр, хуннарның теле, салар, сарыг-уйгур, Фу-йу кыргызлары телләре урын алган.

Белгеч 1982 елда «Фин-угыр җәмгыяте» әгъза-корреспонденты, 1986 елда А.Н. Кононов вафатыннан соң, Совет Тюркологлар Комитеты җитәкчесе итеп сайлана, хәзербу оешма Россия Тюркологлар Комитеты дип атала.

1982 елда Төрек Тел Курумының шәрәфле әгъзасы итеп сайланган Тенишевның «Бюллетень»дә ике мәкаләсе басылган: «Иске Төрекләрдә

әдәби тел бар идеме?», [1986] 1982-1983, 157-161 б.; «Милли әдәби телгә кадәр төрки әдәби телләр», [1994] 1989, 301-307 б.

Мәшһүр галим төрки фән дөньясына 20 фәннәр докторы һәм 30 доцент хәзерләгән. Ә.Р. Тенишевның 60 яшьлек юбилее уңаеннан хезмәттәше профессор Б.А. Серебренников һәм укучысы А.А. Чеченовның «Советская Тюркология» журналында галимгә багышланган мәкаләләре дөнья күргән. Әдһәм Рәхим улының 70 яшенә Төркиядә «Türk Dili Araştırmaları Yıllığı Belleten»ендә галим О.Ф. Серткая мәкалә бастырган, 2007 елда «Modern Türklük Araştırmaları Derğisi»нең бер номеры махсус Ә.Р. Тенишев истәлегенә багышлап чыгарылган (№4).

1998 елда Төркия дәүләт башлыгы Сөләйман Демирел галим Тенишевны Likyat nişanı медале белән бүләкли. Кадерле тюрколог 2004 елда вафат була. Әдһәм Рәхим улының 90 еллыгы уңае белән Төрек Теле Курумы галимгә багышланган китап нәшер итте (Басманы хәзерләүчеләр: Камил Нариман углы; Минара Алиева. Анкара 2013, 208 б.).

1980 еллар ахырында галим белән шәхси танышу форсаты чыгуга чиксез шатмын. Татарчамны яхшырту максаты белән, Россиядә, Казанда уздырылган төрле конференцияләргә еш килергә тырыша идем, Әдһәм Рәхим улы белән шул фәнни тупламнарның берсендә таныштык.

XX гасырның төрле вакыйгаларга бай тарихы эчендә мәрхүм Совет - Татар Тюркологы Әдһәм Рәхим углы Тенишевның миңа язган тәбрикләү хатын кадерле хәтирә итеп саклыйм:

20.12.1996. Күп хөрмәт белән дустым, Мостафа бәй!

Сезне һәм якын туганнарыгызны яңа ел бәйрәмнәре белән котлап, чын күңелдән исәнлек-саулык, ак бәхетләр теләп калам. Яңа ел сезгә төкле аяк белән керсен.

Ихтирам белән Ә. Тенишев.

**Әдәбият**


http://www.mtss.ru/?page=tenishev

http://www.wikiwand.com/ru/Тенишев,_Эдхям_Рахимович

Дыбо, А. В. (2013) Edhem Rahimoğlu Tenişev'in Anısına, *Edhem Rahimoğlu Tenişev Doğumunun 90. Yılına Armağan,* Ankara: Türk Dil Kurumu. – 47–60.

Killi G. (2005) Edhem Rahimoviç Tenişev (1921-11.07.2004) *Modern Türklük Araştırmaları Dergisi* 2(1). – 177– 178.

Serebrennikov, B. A.; Çeçenov, A. Edhem Rahimoviç Tenişev (60. Doğum Yıldönümü Münasebetiyle) *Manas Journal of Social Studies*, Vol. 6, İssue 11, 2004. – S. 79-83.

Sertkaya, O. F., Haberler Prof. Dr. Ethem Rahimoviç TENİŞEV (70. Doğum Yıl Dönümü Dolayısı İle), *Türk Dili Araştırmaları Yıllığı Belleten* [1995] 1992. S. 193– 194.

Tenişeva, Y.A. (2013) Edhem Rahimoğlu Tenişev, Edhem Rahimoğlu Tenişev Doğumunun 90. Yılına Armağan, Ankara: Türk Dil Kurumu. – S. 19–46.